ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

2 д. им. М. Вахитова 02.04.2024

«Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең М.Вахитов исемендәге авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 октябрендәге 3 номерлы гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы белән, 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы редакциядә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең М.Вахитов исемендәге авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 октябрендәге 3 номерлы гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 13 апреленә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең М.Вахитов исемендәге авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 октябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су алу скважинасын ремонтлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. М.Вахитов исемендәге авыл, Үзәк урам, 24 нче йорт адресы буенча 13-00 сәгатьтә гражданнар җыенын уздырырга.

4. Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов